Важашур авыл җирлеге Советы

КАРАР

2023 елнын 14 июне №10

Важашур авыл җирлеге Советының 2005 елның 23 декабрендэге 18 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәнең 4 статьясына үзгәреш кертү хакында

Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәсен законнарга туры китерү максатыннан Важашур авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Важашур авыл җирлеге Советының 2005 елның 23 декабрендэге 18 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Важашур авыл җирлеге депутаты статусы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 1 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7) Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучының шулар нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы булган Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданлыгын туктату, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәүгә рөхсәт бирү төре яисә Россия Федерациясе гражданының яисә, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайланган булырга хокуклычит ил гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы бүтән документы булу;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча, махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы П.Л.Иванов